| | |
|---|---|
| ГЛАВА ТОЙГУЗИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>МЕНДЕЛЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ ТОЙГУҖА<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2020 елның 6 ноябреннән № 2

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Менделеевск муниципаль районы Тойгуҗа авыл җирлегенең Тойгуҗа авылында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 ст. нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Тойгуҗа авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы белән, КАРАР БИРӘ:

1. Тойгуҗа авыл җирлеге Тойгуҗа авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча 2020 елның 18 ноябрендә 12 сәгать 00 минутка гражданнар җыенын билгеләргә. Җыен үткәрү урыны итеп түбәндәге адрес буенча урнашкан Тойгуҗа авыл мәдәният йортын билгеләргә: Тойгуҗа ав., Үзәк ур., 48.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«2021 елда үзара салым кертүгә Менделеевск муниципаль районы Тойгуҗа авыл җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә акча кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән ризалашасызмы?:

- Тойгуҗа авыл юлының техник планын әзерләү,
- спорт залы һәм янгын депосы бинасының техник планын һәм паспортын әзерләү,
- янгын сүндерү машинасын тоту,
- эчә торган суның сыйфатын тикшерүне уздыру, - -
- вак таш сатып алу, - -
- видеокамера сатып алу

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында - www.mendeleevsk.tatar.ru «Тойгуҗа авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга, кабул ителгән көннән алып 3 көн эчендә.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Тойгуҗа авыл җирлеге
Башлыгы Р.А. Сафин